Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР № 7-3

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 7 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 2014 елның 18 октябрендәге “Җир салымы турында” гы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм итү иректе җәмгыяте (ДОСААФ)” Төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе идарәсе рәисе мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Салым кодексының 387 маддәсендәге 2 өлеше, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешенең 3 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Уставы нигезендә, саклану сәләтен, милли иминлекне ныгыту, гражданнарга хәрби-патриотик тәрбия бирүне оештыру мәсьәләләре буенча эшчәнлекне тормышка ашыруга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының “Җир салымы турында” гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советының 07.11.2014 ел №12, 31.07.2015 ел №13, 26.06.2017 ел №4-1, 20.06.2019 ел №3-2, 11.02.2020 ел №2-2 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8 абзац өстәргә:
“Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка ярдәм итү иректе җәмгыяте (ДОСААФ)” Төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе эшчәнлегенең иҗтимагый-дәүләт, коммерциягә карамаган, социаль юнәлешле объектлары астында торган җир кишәрлекләренә карата 0,05%”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Ленин ур., 48А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Тажетдинов